**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**2016 елда Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен тапшыру турында**

Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен бирү комитеты тәкъдимнәрен карап тикшергәннән соң **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының В.Е. Алемасов исемендәге дәүләт премиясен түбәндәгеләргә тапшырырга:

1) техник фәннәр кандидаты, Казан милли тикшеренү технология университеты доценты Билалов Тимур Ринат улына – иң критик флюид торыш өлкәсендә катнашмаларның термодинамик үзенчәлекләрен тикшерүгә зур өлеш кертүе өчен;

2) «Хуҗамәт ремонт-механика заводы» ачык акционер җәмгыяте баш инженеры – баш конструкторы Гыймадиев Айрат Мөнир улына – уңышны җыйганнан соң бөртекләрне эшкәртү өчен нәтиҗәле бөртек чистарту машиналары эшләве һәм аларны производствога кулланылышка кертүе өчен;

3) техник фәннәр кандидаты, А.Н. Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты-КАИ өлкән фәнни хезмәткәре Сәлахов Ришат Риза улына – «Энергиядән нәтиҗәле файдалану технологияләре» фәнни-тикшеренү институты директоры – эчке янулы двигательләрне санлы һәм физик модельләштерү ысулларын кулланып югары нәтиҗәле интеллектуаль суыту системаларын эшләүгә зур өлеш кертүе өчен.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2016 ел, 11 июнь
№ ПУ-526